**Татарстан Республикасы**
**Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре Советы**

# КАРАР

**13.09.2024 ел** **№ 128**

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2023 елның 24 октябрендәге 110 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Нурлат шәһәре Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2023 елның 24 октябрендәге 110 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) 2 процент (әлеге карарның 2 пунктының 7 бүлегендә күрсәтелгән салым салу объектларыннан тыш) түбәндәгеләргә карата:

- Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектлары;

- Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларында.».

1.2. 2 пунктта түбәндәге эчтәлекле 7 пунктны өстәргә:

«7) 2025, 2026, 2027 елларга карата 1,2 процент:

- Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә торган исемлеккә кертелгән 1000 квадрат метрдан артык гомуми мәйданы булган административ-эшлекле үзәкләр һәм сәүдә үзәкләре (комплекслар).».

2. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Нурлат шәһәре Советы Рәисе Д.А. Ишкинеев